# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменения в статью $135^5$ Экологического кодекса Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 марта 2023 года

**Статья 1**

Внести в статью $135^5$ Экологического кодекса Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 1; 2010, № 5 (I часть); 2011, № 6 (I часть), № 10 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I), № 44 (часть I); 2017, № 27 (часть I); 2018, № 54 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 19 (часть I); 2020, № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I); 2021, № 20 (часть I), № 57 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 34 (часть I), № 57 (часть I), № 83 (часть I) изменение, изложив ее в следующей редакции:

«Статья $135^5$. **Порядок распределения разрешений на добычу охотничьих ресурсов между физическими лицами, осуществляющими охоту в общедоступных охотничьих угодьях**

1. Выдача разрешений на добычу охотничьих ресурсов физическим лицам, осуществляющим охоту в общедоступных охотничьих угодьях (далее – охотники), осуществляется уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов.

2. Разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях распределяются между охотниками в пределах квот добычи охотничьих ресурсов, норм допустимой добычи охотничьих ресурсов, норм пропускной способности, установленных в отношении общедоступных охотничьих угодий.

3. Распределение разрешений на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях между охотниками осуществляется в порядке очередности поступления заявлений на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях, за исключением разрешений на добычу охотничьих ресурсов, включенных в утвержденный нормативным правовым актом уполномоченного органа исполнительной власти

Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов перечень охотничьих ресурсов, распределение разрешений на добычу которых осуществляется посредством жеребьевки. Включение охотничьих ресурсов в указанный в настоящей части перечень осуществляется исходя из квот добычи охотничьих ресурсов, норм допустимой добычи охотничьих ресурсов, норм пропускной способности, установленных в отношении общедоступных охотничьих угодий.

4. Подача заявлений на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях, за исключением охотничьих ресурсов, включенных в перечень, указанный в части 3 настоящей статьи, начинается за 10 календарных дней до дня начала открытия сезона охоты на соответствующие вид или группу видов охотничьих ресурсов и продолжается до дня окончания срока сезона такой охоты. В случае, если день начала подачи заявлений приходится на выходной или праздничный день, подача заявлений начинается в день, предшествующий выходному или праздничному дню.

5. Распределение разрешений на добычу охотничьих ресурсов, включенных в перечень, указанный в части 3 настоящей статьи, осуществляется посредством жеребьевки между охотниками, подавшими в уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов заявления на участие в жеребьевке.

6. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов определяет место, дату и время проведения жеребьевки, количество распределяемых посредством жеребьевки разрешений на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях (по видам охотничьих ресурсов и по муниципальным образованиям), срок подачи заявлений на участие в жеребьевке, который не может составлять менее 10 календарных дней, и размещает указанную информацию на своем официальном сайте в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» не позднее чем за три календарных дня до даты начала приема заявлений на участие в жеребьевке. Дата проведения жеребьевки должна обеспечивать возможность подачи по ее итогам заявлений на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях не менее чем за 10 календарных дней до дня начала открытия сезона охоты на соответствующие вид или группу видов охотничьих ресурсов.

7. По каждому виду охотничьих ресурсов один охотник вправе подать не более одного заявления на участие в жеребьевке. В заявлении на участие в жеребьевке указываются:

1) фамилия, имя, отчество (при наличии) охотника, адрес его места жительства (пребывания, фактического проживания), контактный телефон, сведения об охотничьем билете (серия, номер и дата выдачи);

2) наименование одного муниципального образования, в границах которого располагаются общедоступные охотничьи угодья, на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов на территории которых претендует охотник;

3) вид охотничьих ресурсов;

4) согласие на обработку персональных данных.

8. Форма заявления на участие в жеребьевке утверждается уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов.

9. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов осуществляет проверку заявлений на участие в жеребьевке и содержащихся в них сведений, а также соблюдения установленного срока подачи заявлений на участие в жеребьевке и в срок не позднее трех рабочих дней со дня поступления заявления на участие в жеребьевке принимает решение о допуске охотника к жеребьевке или об отказе в допуске к участию в жеребьевке.

10. Основаниями отказа в допуске к участию в жеребьевке являются:

1) несоответствие требованиям, установленным частями 7 и 8 настоящей статьи;

2) установление факта недостоверности представленных охотником сведений;

3) несоблюдение установленного срока подачи заявлений на участие в жеребьевке.

11. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов формирует по видам охотничьих ресурсов и по муниципальным образованиям списки охотников, допущенных к участию в жеребьевке, а также списки охотников, которым отказано в допуске к участию в жеребьевке, размещает их на своем официальном сайте в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» не позднее чем за три календарных дня до окончания срока подачи заявлений на участие в жеребьевке и актуализирует их не реже чем один раз в каждый последующий рабочий день. Итоговые списки размещаются в срок не позднее трех рабочих дней со дня окончания приема заявлений на участие в жеребьевке.

12. Жеребьевка проводится комиссией, создаваемой уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов. В состав комиссии включаются представители общественности.

13. Жеребьевка проводится методом генерации случайных чисел с использованием информационных систем (электронных сервисов) или с применением лототрона, в который помещаются конверты (контейнеры) с номерами. Жеребьевка проводится публично, при ее проведении могут присутствовать охотники, их представители, представители средств массовой информации.

14. По результатам жеребьевки составляется протокол, который подписывается всеми членами комиссии, присутствовавшими при проведении жеребьевки. В протоколе указываются:

1) охотники, которые приобрели право на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях (с указанием вида охотничьих ресурсов и муниципального образования);

2) охотники, которые могут приобрести право на получение разрешения на добычу заявленных охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях в

случаях, установленных частями 17 и 18 настоящей статьи (не менее пяти лиц по каждому виду охотничьего ресурса в каждом муниципальном образовании), с указанием очередности, установленной при проведении жеребьевки.

15. Информация об итогах жеребьевки размещается на официальном сайте уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» в срок не позднее трех рабочих дней со дня проведения жеребьевки.

16. Для получения разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях по результатам жеребьевки охотники, указанные в пункте 1 части 14 настоящей статьи, обращаются с заявлениями на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях в уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов в течение 10 рабочих дней со дня размещения информации об итогах жеребьевки на официальном сайте уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

17. В случае, если право на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях не реализовано охотниками, указанными в пункте 1 части 14 настоящей статьи, в срок, установленный частью 16 настоящей статьи, право на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях предоставляется в порядке очередности охотникам, указанным в пункте 2 части 14 настоящей статьи.

18. В случае увеличения в порядке, установленном законодательством Российской Федерации, в течение сезона охоты квот, норм добычи охотничьих ресурсов, норм пропускной способности общедоступных охотничьих угодий, нормативов допустимого изъятия охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях право на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях предоставляется в порядке очередности охотникам, указанным в пункте 2 части 14 настоящей статьи.

19. Информация о возникновении права на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях у охотников, указанных в пункте 2 части 14 настоящей статьи, размещается на официальном сайте уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

20. Право на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях в случаях, предусмотренных частями 17 и 18 настоящей статьи, действует в течение 10 рабочих дней со дня размещения информации о возникновении такого права на официальном сайте уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет». Для получения разрешения на добычу

охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях охотники, у которых возникло право на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях, обращаются с заявлениями на получение разрешения на добычу охотничьих ресурсов в общедоступных охотничьих угодьях в уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов в срок, установленный настоящей частью.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
06 апреля 2023 года
№ 29-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^{5}$ статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының $135^{5}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$135^{5}$ статья. **Аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык белән шөгыльләнүче физик затлар арасында бүлү тәртибе**

1. Һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык итүче физик затларга (алга таба – аучылар) аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләр бирү аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла.

2. Һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләр аучылар арасында һәркем файдалана алырлык аучылык җирләренә карата билгеләнгән аучылык ресурсларын аулауга квота, аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт ителгән нормалар, мондый җирләрнең аучыларны сыйдыру нормалары чикләрендә бүленә.

3. Һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне аучылар арасында бүлү һәркем файдалана алырлык аучылык

җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга гариза тапшыру чираты тәртибендә гамәлгә ашырыла, моңа, аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органының норматив хокукый акты белән расланган аучылык ресурслары исемлегенә кертелеп, аулауга рөхсәтләр шобага салу юлы белән бүленә торган аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләр керми. Аучылык ресурсларын әлеге өлештә күрсәтелгән исемлеккә кертү һәркем файдалана алырлык аучылык җирләренә карата билгеләнгән аучылык ресурсларын аулауга квотаны, аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт ителгән нормаларны, мондый җирләрнең аучыларны сыйдыру нормаларын истә тотып башкарыла.

4. Һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын, әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән аучылык ресурсларыннан тыш, аулауга рөхсәтләр алуга гаризалар тапшыру, аучылык ресурсларының тиешле төренә яки төркеменә ау сезоны ачылырга 10 календарь көн кала башлана һәм мондый ау сезоны беткән көнгә кадәр дәвам итә. Гаризалар тапшыру башланган көн ял яки бәйрәм көненә туры килгән очракта, гаризалар бирү ял яки бәйрәм көненә кадәр булган көнне башлана.

5. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән аучылык ресурсларын аулауга рөхсәтләрне бүлү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына шобага салуда катнашу өчен гариза биргән аучылар арасында шобага салу юлы белән башкарыла.

6. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы шобага салуны үткәрү урынын, датасын һәм вакытын, һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга шобага салу юлы белән бирелә торган рөхсәтләр санын (аучылык ресурслары төрләре буенча һәм муниципаль берәмлекләр буенча), шобага салуда катнашу өчен гаризалар тапшыруның 10 календарь көннән дә ким булмаган вакытын билгели һәм күрсәтелгән мәгълүматны, шобага салуда катнашу өчен гаризалар кабул ителә башлау датасына кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында урнаштыра. Шобага салуны үткәрү датасы аның нәтиҗәләре буенча аучылык ресурсларының тиешле төренә яки төркеменә ау сезоны ачылырга ким дигәндә 10 календарь көн кала һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга гаризалар бирү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

7. Аучылык ресурсларының һәр төре буенча шобага салуда катнашу өчен бер аучы бер генә гариза бирә ала. Шобага салуда катнашу өчен гаризада түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) аучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны (тору, фактта яшәү) адресы, элемтә өчен телефоны, аучылык билеты турында белешмәләр (серия, номер һәм бирелү датасы);

2) аучы тарафыннан территориясендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу дәгъва кылынган һәркем файдалана алырлык аучылык җирләре урнашкан бер муниципаль берәмлек исеме;

3) аучылык ресурсларының төре;

4) персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык.

8. Шобага салуда катнашу өчен тапшырыла торган гаризаның рәвеше аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы тарафыннан раслана.

9. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы шобага салуда катнашу өчен гаризаларны һәм андагы белешмәләрне, шулай ук шобага салуда катнашу өчен гаризалар тапшыруның билгеләнгән срогы үтәлешен тикшерә һәм, шобага салуда катнашу өчен гариза кергән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, аучыга шобага салуда катнашырга рөхсәт бирү яки шобага салуда катнашырга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Шобага салуда катнашырга рөхсәт бирүдән баш тартуның нигезләре түбәндәгеләр:

1) әлеге статьяның 7 һәм 8 өлешләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

2) аучы биргән белешмәләрнең ялган булу факты билгеләнү;

3) шобага салуда катнашуга гаризалар тапшыруның билгеләнгән срогын үтәмәү.

11. Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы аучылык ресурслары төрләре һәм муниципаль берәмлекләр буенча шобага салуда катнашырга рөхсәт бирелгән аучылар исемлеген, шулай ук шобага салуда катнашырга рөхсәт бирелмәгән аучылар исемлеген төзи, аларны шобага салуда катнашу өчен гаризалар тапшыру срогы тәмамланырга кимендә өч календарь көн кала «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында урнаштыра һәм аларны алдагы һәр эш көнендә кимендә бер тапкыр актуальләштерә. Йомгаклау исемлекләре шобага салуда катнашу өчен гаризалар кабул итү тәмамланган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

12. Шобага салу аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан төзелә торган комиссия тарафыннан үткәрелә. Комиссия составына җәмәгатьчелек вәкилләре кертелә.

13. Шобага салу мәгълүмат системаларын (электрон сервислар) кулланып очраклы саннар чыгу ысулы белән яисә номерлар салынган конвертлар (контейнерлар) урнаштырыла торган лототрон кулланып үткәрелә. Шобага салу халык алдында үткәрелә, аны уздырганда аучылар, аларның вәкилләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга мөмкин.

14. Шобага салу нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелә, ул шобага салуны үткәрүдә катнашкан барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы бирелгән аучылар (аучылык ресурсларының төрен һәм муниципаль берәмлекне күрсәтеп);

2) әлеге статьяның 17 һәм 18 өлешләрендә билгеләнгән очракларда, шобага салу үткәргәндә билгеләнгән чиратны күрсәтеп, һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы бирелергә мөмкин булган аучылар (һәр муниципаль берәмлектә аучылык ресурсларының һәр төре буенча кимендә биш зат).

15. Шобага салу нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат шобага салу үткәрелгән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

16. Шобага салу нәтиҗәләре буенча һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу өчен, әлеге статьяның 14 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән аучылар, аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында шобага салу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән алып 10 эш көне эчендә, аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органына һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга гариза белән мөрәҗәгать итәләр.

17. Һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы әлеге статьяның 14 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән аучылар тарафыннан әлеге статьяның 16 өлешендә билгеләнгән срокта гамәлгә ашырылмаган очракта, һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы чират тәртибендә әлеге статьяның 14 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән затларга бирелә.

18. Аучылык сезоны дәвамында һәркем файдалана алырлык аучылык җирләренә карата билгеләнгән квота, аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт ителгән нормалар, мондый җирләрнең аучыларны сыйдыру нормалары, һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт ителгән нормативлар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә арттырылган очракта, һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы әлеге статьяның 14 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән аучыларга чират тәртибендә бирелә.

19. Әлеге статьяның 14 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән аучыларга һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы барлыкка килү турында мәгълүмат аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

20. Әлеге статьяның 17 һәм 18 өлешләрендә каралган очракларда һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алуга хокук мондый хокук барлыкка килү турындагы мәгълүмат аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма

хакимияте вәкаләтле органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган көннән алып 10 эш көне дәвамында гамәлдә була. Һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу хокукы барлыкка килгән аучылар һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу өчен һәркем файдалана алырлык аучылык җирләрендә аучылык ресурсларын аулауга рөхсәт алу турындагы гариза белән әлеге өлештә билгеләнгән срокта аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органына мөрәҗәгать итәләр.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 06 апрель
№ 29-ТРЗ